КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 июль г.Казань № 817

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климаты торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1459 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының илкүләм рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климаты торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2022 ел, 30 декабрь, 1459 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 10 апрель, 435 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 8 пунктның өченче абзацындагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин